**Исполнительный комитет Александро-Слободского сельского поселения Заинского муниципального района Республика Татарстан**

Ул. Центральная, д. 73 с. Ал. Слобода, Заинский район, 423503

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты**

Узәк урамы, 73 нче йорт, Ал.Слобода авылы, Зәй районы, 423503

Телефон, факс 6-27-30. Электронный адрес: Aslob.Zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«03» февраль 2023 г.** **№3**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2023 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2023 елның 30 январендәге 119 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге Уставына таянып,

**карар бирәм:**

1.2023 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7793,48 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.“Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Александр Бистәсе авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында” 2022 елның 02 февралендәге 02 номерлы Татарстан Республикасы Зәй

муниципаль районы Александр Бистәсе авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.Г.Варганова**

Зәй муниципаль районы
Александр Бистәсе авыл җирлеге
башкарма комитетының
03.02.2023ел
4 номерлы карарына
1 нче кушымта

2023 елның 01 февраленнән
Александр Бистәсе авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2964,25 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1266,98 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3562,25 |
| Барысы | 7793,48 |

Зәй муниципаль районы
Александр Бистәсе авыл җирлеге
башкарма комитетының
03.02.2023ел
4 номерлы карарына
2 нче кушымта

Александр Бистәсе авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 812,8 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2212,17 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1236,69 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3531,82 |
| Барысы | 7793,48 |